Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№33 (126)

27 ноябрь 2014 ел



# Йолдызлар кабынган җирдә!

Казан – яшьлек, егәрлек, көч-куәт шәһәре. Шуңа күрә дә ул үзенә шундый ук энергияле, позитив кешеләрне җәлеп итә. 25 ноябрь көнне Универсиада авылында урнашкан Идел буе физик тәрбия, спорт һәм туризм академиясенең концертлар залында уздырылган чара шуңа дәлил булып тора. Бу көнне бөтен Россия студентларының иң-иңнәре барланды.

• Туган тел сагында

# Саклыйбыз һәм үстерәбез!

Туган телләр һәм мәдәниятләрне саклау һәм үстерү мәсьәләсе республика, илебездә генә түгел, хәтта бөтендөнья күләмендә дә социаль-мәдәни проблемаларның иң мөһимнәреннән санала. Шундый актуаль мәсьәләләрне хәл итү юлларын Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты базасында узган «Телләрне һәм мәдәниятләрне саклау һәм үстерү» дип исемләнгән III Халыкара фәнни-гамәли форумда эзләделәр.

**Дания ФАТЫЙХОВА**

Хәзерге вакытта кешеләрнең үзләре өчен яңа кыйммәтләр булдыру, башка халыкларның мәдәниятләре призмасы аша гомумкешелек кыйммәтләренә, мәдәниятара аралашуга йөз тоту юнәлешендә эшләүләре бигрәк тә мөһим. Әлеге мәсьәләне эффектив рәвештә хәл итү өчен, җәмгыятьтә тел һәм культурологик белем бирүнең социаль мөһимлеген арттыру, яшь буын вәкилләрендә үзләренең һәм башка халыкларның, мәдәниятләренә карата хөрмәт хисен тәрбияләү зарурияте барлыкка килде.



Казан университеты эшчәнлегендә лингвистик юнәлеш һәрвакыт алдынгы позицияләрдә булган, шуңа күрә уку йортыбызда әлеге темага багышланган чаралар бик еш үткәрелә. Бу арада 3 көн буе дәвам иткән форум кысаларында барлыгы 2 пленар утырыш, 19 секция утырышы, 6 түгәрәк өстәл, 4 мастер-класс уздырылды. Анда туган тел һәм мәдәниятләрне үстерү перспективалары, аларны саклап калу һәм алга җибәрү өлкәсендә дәүләт сәясәтенең ярдәме, тел һәм әдәбиятларны чагыштырма-тарихи ракурста өйрәнү, хәзерге заман күпмилләтле пространствода тел бердәйлекләре, хәзерге чор шәһәрләренең әдәби-тарихи тирәлеген саклау проблемалары һ.б. кызык темаларга фикер алыштылар.

Форумның географиясе дә елдан-ел киңәя бара. Быел, тел мәсьәләләре турында сөйләшү өчен, Татарстан һәм Россия вәкилләреннән тыш, Германия, Финляндия, Төркия, Латвия, Казахстан, Үзбәкстан һ.б. ил галимнәре дә килгән иде.

Форумның ачылышы бик тантаналы рәвештә узды. Анда КФУ ректоры И.Гафуров, ФһМБИ директоры Р.Җамалетдинов, ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Р.Вәлиев, Россия мәгариф һәм фән министрлыгының балалар һәм яшьләрне тәрбияләү өлкәсендәге Дәүләт сәясәте департаментының Халыкара хезмәттәшлек һәм рус телен үстерү бүлеге җитәкчесе С.Брызгалова һ.б. мөхтәрәм кунаклар катнашты. Алар барысы да чыгышларында әлеге юнәлешне үстерүдә КФУның, шулай ук ФһМБИнең әһәмиятле ролен билгеләде, форумның мөһимлегенә басым ясады.

Чара кысаларында татар телле булмаган студентлар һәм магистрлар өчен татар теле буенча Республика вузара студентлар олимпиадасы да уздырылды. Бу олимпиада уку йортыбызда инде җиденче мәртәбә үткәрелә. Быел анда барлыгы 103 гариза кабул иткәннәр. Бу сан башка еллар белән чагыштырганда шактый арткан. Димәк, яшьләр арасында татар теленә игътибар арта дигән сүз.

Олимпиаданың ачылышында татар телен өйрәнгән чит ил галимнәре – Төркиянең Эгей университеты профессоры Мостафа Өнәр, Финляндиянең Хельсинки университеты лекторы Кадрия ханым Бәдретдин белән бергә ФһМБИның уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары Рамил Хәмит улы Мирзаһитов һәм Г.Тукай ис. татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге мөдире Әлфия Шәүкәт кызы Юсупова катнашты. Олимпиада ике өлештән: язма һәм телдән сөйли торган биремнәрдән гыйбарәт булган. Алар югары белем бирү стандартлары нигезендә әзерләнгән. Бәйгенең җиңүчеләре тантаналы рәвештә Туган тел көнендә бүләкләнәчәк.

• Ел студенты

# Йолдызлар кабынган җирдә!

**Илмир ВӘЛИЕВ,** Математика һәм механика институты

«Ел студенты-2014» Россия милли премиясе илебез күләмендә тәүге мәртәбә «Студентлы Россия» Бөтенроссия форумы кысаларында уздырылды.

Чараны нәкъ менә Казанда үткәрү идеясе ТР «Ел студенты-2013» бәйгесе финалында тәкъдим ителгән иде. Әлеге инициативаны республикабыз Президенты Р.Миңнеханов та яклап чыкты.

Конкурста Россиянең 45 төбәгеннән 400гә якын студент катнашырга теләк белдергән. Иң алдынгы студентлар барлыгы 9 профильле номинациядә һәм гран-при өчен көч сынашты. «Россиянең студентлары һәм студент берләшмәләре ассоциациясе» Бөтенроссия иҗтимагый яшьләр хәрәкәте рәисе В.Адерхин сүзләренчә, катнашучыларюгары өлгереш, академик «бурыч»ларның булмавы һәм теге яки бу юнәлештә ачыш ясау критерийлары буенча бәяләнгән.

Дәрәҗәле премиягә Татарстанның 4 вәкиле лаек булды. КФУ студенты Илһам Галиуллинга «Ел ачышы» номинациясендә тиңнәр булмаган. Астрономия, физика һәм башка бик күп өлкә белән кызыксынучы егет үзенең берничә йолдызын да ачарга өлгергән. «Ачкан йолдызларымны әти-әниемә багышлыйм. Шулай ук бүгенге һәр катнашучыга үз йолдызын ачуларын телим», – диде Илһам. «Ел спортчысы» номинациясендә исә Идарә, икътисад һәм хокук институты студенты А.Корнилов, Казан милли тикшеренү-технология университеты студентлары К.Бутусов «Иҗади шәхес», ә Л.Диярова «Елның студентлар лидеры» номинацияләрендә җиңүчеләр дип табылды.

Гран-при иясен игълан итү өчен сүз И.Халиковка бирелде. «Әлеге искиткеч матур һәм гомергә истә калырлык чараның Казанда узуы безнең өчен зур горурлык. Бүген биредә Россиянең иң әйбәт студентлары җыелган һәм сезнең һәрберегез җиңүче», – диде премьер- министр һәм катнашучыларга чарадагы онытылмас мизгелләрнең гомерлеккә истә калуын теләде. Бәйгенең иң төп бүләгенә Ставрополь дәүләт аграр университеты студенты Екатерина Войтышева лаек булды. Аңа «Ел студенты-2014» исеме бирелде һәм 200 мең сумлык сертификат тапшырылды. Шулай ук, Екатерина РФ мәгариф һәм фән министрлыгының иҗтимагый утырышларында катнаша алу мөмкинлегенә ия булды.

Бүләкләү тантанасы «La Primavera» Казан камера оркестры, ТРның атказанган артисткасы Э.Кәлимуллина, «Мураками» төркеме солисткасы Д.Ваһапова һәм башка күренекле артистлар чыгышлары белән үрелеп барды.

• Без кунакта

# «Идел-пресс» буйлап сәяхәт

**Лилия ЯКУПОВА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Г.Тукай ис. татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегенең татар әдәбияты, укыту методикасы кафедрасы доценты Таһир Шәмсегалиевич җитәкчелегендә «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире Миңназыйм абый Сәфәров белән булган очрашу һәм редакциягә сәяхәтебез турында алдагы саннарда инде хәбәр иткән идек. Бу мәкаләдә исә шушы очрашуларның дәвамы буларак, киләчәктә студент тормышыбыздан иң күңелле хатирәләрнең берсе булып күңелләребезгә кереп калырлык «Идел-пресс» нәшриятына сәяхәтебез турында язасым килә.

Күпләребез беләдер, әлеге полиграфия-нәшрият оешмасы «Татмедиа» бинасы белән янәшә урнашкан. Беренче карашка, ул гадәти һәм узып-китеп йөрүчеләрдә әллә ни кызыксыну уятмый сыман. Әмма якыннанрак танышканнан соң, анда, без ияләшкән дөньядан тыш, үзең өчен бик тә кызыклы һәм могҗизалы икенче бер дөньяны ачасың. Биредә дә нәкъ безнең кебек гадәти кешеләр хезмәт итә. Әмма бүгенге яшәешебез алар хезмәтеннән башка һич мөмкин түгел! Алар кешегә һәр көн яңалык алып килә торган газета-журналлар, рухи азык бирә торган китаплар чыгаралар. Нәшрият эшенең дә үзенчәлекле, һөнәри осталык сорый торган нечкә яклары шактый күп икән. Боларның барысы белән дә безне шушы предприятиедә җаваплы вазыйфа башкаручы Светлана ханым һәркайсыбызга үтемле һәм мавыктыргыч итеп таныштырды.



«Идел-пресс» РФдә иң зур полиграфия-нәшрият предприятиеләренең берсе булып тора. Ул 4 катлы бинада урнашкан. Һәр этажда нәшрият эшендә файдаланыла торган берсеннән-берсе зур автомат машиналар урын алган. Газета, журнал яки китап басуларына карап, я булмаса, басманың таләп ителгән сыйфатына бәйле рәвештә, аларның төрле төрләре бар. Машиналарның яшьләре дә төрле, СССР чорыннан калганнарыннан алып, бүгенге заман технологик үзгәрешләрнең бар таләпләренә дә җавап бирерлекләрен дә күрергә мөмкин биредә.

Бер сәгать эчендә китап чыгару, матбагачылык һәм газета-журналлар нәшер итү эше күз алдыннан узды. Борынгы заманнарда китапларны кулдан күчергәннәр, шуңа күрә алар бик тә кадерле һәм кыйммәтле булган. Ә хәзерге вакытта инде бу авыр хезмәтнең күп өлешен машиналар башкара. Соңгы 20-25 ел эчендә генә дә матбагачылыкта зур яңарыш, матур мәгънәсендә технологик революция булган. Бүген күз иярмәстәй тизлектә эшли торган катлаулы машиналар кеше кулы белән идарә ителә. Шул ук машиналар да кеше хезмәтенең җимеше бит! Кеше хезмәте бәһасез.

«Идел-пресс» полиграфия-нәшрият предприятиесендә булу китапчылык хезмәтенең безгә күп нечкәлекләрен ачты, моңа кадәр дә зур хөрмәт белән кулланылган китапка, аны нәшер иткән кешеләрнең эшчәнлегенә ихтирам, китапка сак караш, җаваплылык хисе икеләтә артты. Безнеңчә, нәшрият предприятиеләре эшчәнлеге белән таныштыруны мәктәп укучыларыннан ук башларга кирәк. Бу танышлык китапка, белемгә мәхәббәт, хөрмәт хисе тәрбияләүдә зур этәргеч булыр иде.



● Әдәби атна

24 ноябрь көнне Г.Тукай ис. татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге, Татарстан районнарыннан тыш, Башкортстан, Пермь, Киров өлкәсеннән һәм Чувашиядән килгән мәктәп укучылары һәм укытучыларын кунак итеп җибәрде. Бу көнне «Илһамлы каләм» һәм «Шигъри Сабантуй» бәйгеләренең йомгаклау тантанасы булды. Чарада бәйгенең икенче турына үткән укучылар катнашты.

# Милли моңлы бәйгеләр

**Эльвина НӘҖИПОВА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Кая гына барсак та, кайда гына яшәсәк тә, безне татар моңы йокыдан уята, озата, уйландыра, юксындыра, юата. «Милли моң – ул әсәрнең җаны», – дигән Х.Сарьян. Бу моң ике конкурста катнашучыларның да иҗат җимешләрендә зур урын алган иде.

Бәйгеләргә эшләр 1 марттан 31 октябрьгә кадәр кабул ителде. «Шигъри сабантуй»га шигърият буенча эшләр килсә, «Илһамлы каләм»гә проза, драматургия һәм публицистика буенча эшләр кабул ителде. Бу ике бәйгедә катнашкан әсәрләргә бәяне танылган шагыйрь һәм язучылар, галим-укытучылардан торган мәртәбәле жюри бирде. Бу көнне катнашучылар поэзия, проза, публицистика, драма өлкәләре буенча мастер-классларда катнашты.



«Шигъри Сабантуй» бәйгесе буенча дүрт кызыксындыру бүләге, укучылар арасында «Яшь батыр» (җиңүче – Теләче районы Баландыш урта мәктәбенең 9 сыйныф укучысы Илсаф Тимербаев) һәм студентлар арасында «Сабантуй батыры» (җиңүче – татар филологиясенең 4 курс студенты Ләйлә Хәбибуллина) номинацияләре каралган иде.

«Илһамлы каләм»нең иҗат мәйданы тагын да киңрәк. Биредә проза, публицистика, драма буенча 9-11 сыйныф укучылары көч сынашты һәм җиңүчеләр билгеләнде. Моннан тыш, махсус дүрт номинация дә каралган иде. Проза буенча 1 нче урынны Казан шәһәре 7 нче номерлы лицей-интернатының 10 сыйныф укучысы Булат Насыйбуллин яулады. Публицистикада беренчелекне Сарман районы Сарман гимназиясенең 10 сыйныф укучысы Гөлинә Нәгыймова алды, ә драма өлкәсендә – Чирмешән районы Лашман урта мәктәбенең 11 сыйныф укучысы Алсинә Галимова.

Җиңүчеләргә истәлекле бүләкләр, укытучыларына рәхмәт хатлары тапшырылды. Катнашучыларның һәммәсенә катнашу таныклыгы бирелде. Бәйрәм тантанасы җыр, шигырьләр белән үрелеп барды.

Әлеге бәйгеләргә җаваплы филология фәннәре докторы Ләйлә Ихсан кызы Минһаҗева һәм филология фәннәре кандидаты, доцент Халисә Хатыйп кызы Кузьмина тарафыннан зур эш башкарылды. Ләйлә Ихсановна тарафыннан укучы-укытучыларга әйтелгән үгет-нәсыйхәт һәм изге теләкләр бәйгеләрнең якты киләчәге булачагына этәргеч ясады.

«Илһамлы каләм» һәм «Шигъри Сабантуй» – ул учак, ялкын! Киләчәктә дә бәйгене оештыручыларның тырыш хезмәте, катнашучылар белән даими элемтәсе әлеге ялкынны сүрелдермәс.

# «Милләт язмышына битараф булмасагыз иде!»



Күптән түгел Татарстан Язучылар берлегенең Тукай клубында яшь язучылар семинары узды. Иҗади сәләтләре булган яшьләрне барлау, аларның осталыкларын үстерү берлекнең төп максатларыннан берсе булып тора. Ник дигәндә, яшь иҗатчылары булмаган әдәбиятның киләчәге шикле.

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Семинарга республиканың 20 районыннан 50гә якын яшь язучы һәм шагыйрь җыелды. Араларында студентлар күпчелекне тәшкил итте. Яшь иҗатчылар җыенын Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан ачып җибәрде. Аның сүзләренчә, бүген Татарстан язучыларының уртача яше 70 тирәсендә. Шуңа да әдәби агымга, берлек эшчәнлегенә яшьләрне тарту бик мөһим һәм кирәкле эш. «Хәзерге көндә Татарстанның шәһәр һәм районнарындагы, авылларындагы, чит төбәкләрдәге әдәби берләшмәләрне барлап, аларны Татарстан Язучылар берлеге түбәсе астына туплау максаты куелды», – дип җиткерде ул үз чыгышында.

Семинарның ачылышында өч яшь иҗатчыны Язучылар берлегенә кабул иттеләр. Бу дәрәҗәгә барыбызга да яхшы таныш, кайчандыр Казан университетының «Әллүки» берләшмәсендә чыныгу алган шагыйрьләр Э.Һадиева, Б.Ибраһимов һәм Чаллыда чыгып килә торган «Мәйдан» журналы әдәби хезмәткәре Ф.Мәҗитов лаек дип табылды. Аларга таныклыкны Язучылар берлегенә кабул итү коллегиясе җитәкчесе Т.Галиуллин үзе тапшырды.

«Әлбәттә, яшь каләм тибрәтүче өчен Язучылар берлегенә эләгү үзмаксат булырга тиеш түгел. Ничек кенә пафослы яңгыраса да, аның төп бурычы – халыкка, милләткә хезмәт итү. Шуңа да яшьләребезнең сөю-сөелү, мәхәббәт турында гына язмыйча, милләт язмышы темасына да мөрәҗәгать итүләрен телисе килә», – дип белдерде әдип.

Семинарның төп өлешендә яшь язучылар өчен остаханәләр оештырылды. Э.Шәрифуллина, Т.Галиуллин, Ф.Мөслимова, Р.Гаташ, И.Иксанова, Р.Рахмани, Р.Рахман, М.Вәлиев, Н.Гыйматдинова, М.Закир, Г.Гыйльманов, Р.Хәмит, Г.Рәхим, З.Мансуров, М.Галиев, Р.Сәгъди, Й.Җамалетдинова, төркемнәргә бүлеп, әдәби өлкәдә тәүге адымнарын ясаучы егет-кызлар белән аралашты, аларның әсәрләрен анализлады, алтынга тиң киңәшләрен бирде.



# Акчарлаклар канат кага

**Раил САДРЕТДИНОВ,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Гүзәл табигатьле урман аланында урнашкан «Идел» эчендә акчарлаклар кайнаша. Акчарлакларның да гадиләре түгел, иҗади, фикерле, әдәбият, татар теле дип җан атучылары. ТР Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, «Идел» яшьләр үзәге тарафыннан оештырылган «Иделем акчарлагы» бәйгесе менә инде 14 нче ел рәттән татарның яшь язучыларын әдәбият мәйданында бил алышырга җыйды. Бәйгедә җиңүчеләр арасында КФУ студентларының булуы аеруча да күңелле.

## Нәрсә ул «Иделем акчарлагы» яки Иделнең үз акчарлаклары

Әдәбиятыбызга бу катлаулы чорда кемнәр килә, ничек килә, кайдан килә? Әдәбиятта буын яңарту, дәвамчанлык соңгы арада җәмәгатьчелектә зур резонанс тудырган мәсьәләләрнең берсе. ТР Язучылар Союзында бүген 300дән артык әгъза исәпләнә. Яшеренбатырын түгел, күбесе олы яшьтәгеләр. Гасырлардан килгән әдәбиятыбыз үзенә зур ташкын булып килеп кергән каләм әһелләре чорын да, аларга кытлык кичергән вакытларны да яхшы хәтерли. Икътисад, сәнгатьтә дулкынсыман үсеш булган кебек, әдәбиятыбыз да бу яшәеш кануныннан чыгарма түгел. Табигать шулай яратылган: һәр тереклек иясе үзеннән соң буын калдырырга омтыла.



Быел бәйгегә 70тән артык эш кабул ителгән. 43 катнашучы йомгаклау өлешенә чакырылды. Конкурс 2 этаптан гыйбарәт. Беренчесендә эшләр кабул ителә. Олпат язучыларыбыздан торган жюри тарафыннан сайлап алынган эшләр икенче этапка үтә.

## Әдәбият, кальбеңдә ни бар?..

Ачылыш тантанасында катнашкан шагыйрә, журналист, «Түгәрәк уен» альманахы баш мөхәррире Илсөяр Иксанова бәйгенең максатын болай билгеләде: «Иделем акчарлагы» – сезнең өчен әдәби мәктәп ул. Кеше өчен иң зур бәхет – аралашу, дигән Сент-Экзюпери. Бәйгенең төп максаты да – аралашу мәйданы булдыру».

Кабул ителгән эшләрнең күбесе һәрвакыттагыча әдәбият таҗы – поэзия номинациясендә. Жюри әгъзалары моны әдәбиятның шигъри формада яралуы, шул кагыйдәгә бүген дә тугры булып калуы, иҗатның бу төрендә чиксез мөмкинлекләр булу белән аңлатты. Прозабыз аксый, дигән фикер яшәп килсә дә, соңгы арада хатын-кыз прозаикларыбызның активлашуы сизелә икән. Тел тоемлау, әлеге хәзинәдән дөрес һәм максатчан файдалану бүген дә чишелмәгән мәсьәлә булып кала бирә. «Телгә игътибар кимеде, әдәбият укымыйча гына язарга өйрәнеп булмый», – диде шагыйрь, жюри рәисе Г.Морат. И.Иксанова фикеренчә, әбиләребезнең җор телле мәкаль-әйтемнәре югала бару да моңа китереп суга икән.

Бәйге кызыклы очрашулары, мастер-класслары, жюри тарафыннан үз иҗатыңа карата әйтелгән фикерләре, тәнкыйть, аралашу белән катнашучылар күңелендә әле озак саклаunion. Бәлки, кемнәрнеңдер, кайтканнан соң, иң яхшы дип бәяләнерлек иҗат җимешләре туар. Иң мөһиме: бер җирдә туктап калмыйча, иренмичә, авырлыкларны җиңеп, күңел төшенкелегенә бирешмичә алга бару.

## Күрегез, кем килә!

2013 елгы бәйгедә гран-прига лаеклы кеше табылмаса, быел исә, зур җиңүгә прозада Чулпан Гобәйдуллина (Арча районы), поэзиядә Нурлан Ганиев (Башкортстан Республикасы) лаек дип табылды. Чулпан хәзерге көндә Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегенең 5 курсында белем ала.

Каләм алган хур булмас, ди халык мәкале. Иҗат юлына басканбыз икән, күкләребез аяз, юлыбызда дулкын, зилзиләләр очрамасын иде. Тын гына, дулкыннарга бирешмичә очыгыз, акчарлаклар!

**• Яшьлек-яңарыш**

Салкын Казанның «Татнефть-арена» боз сараенда бу көннәрдә җәй көне сыман эссе булды. Ни өчен дисезме?.. Быел Казан төрки дөньяның мәдәни башкаласы, дип игълан ителде. Ә бу, әлбәттә, «Turkvizion-2014» бәйгесен нәкъ менә Казанда уздырырга мөмкинлек бирде.

# Төрек-татар Евровидениесе яки Turkvizion




**Нурия ГАЙСАРОВА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты



«Turkvizion» – популяр бәйгеләрнең берсе. Беренче тапкыр конкурс 2013 елда Төркиянең Искешәһәр каласында узган иде. Музыкаль фестиваль буларак, «Turkvizion» конкурсы төрек телерадиокомпаниясе ярдәме белән барлыкка килә. Конкурс Евровидениегә охшаган. Аның төп максаты – төрки илләрнең һәм төбәкләрнең катнашуында төрек музыкасын пропагандалауда. «Turkvizion» нинди бәйге соң ул, дип сорау биргәндә, ул – халыкара төрки җырлар конкурсы, төрки музыка, җырларны башкаручы барлык җырчыларны бер сәхнәдә җыючы халыкара проект, дип җавап бирү дә дөрес булыр.

Быел бу конкурсны уздыру Татарстаныбызга тапшырылды. Бу юкка гына түгел... Республикабызда төрле конфессияләр, милләтләр инде менә ничә гасырлар дәвамында дустанә яши. Шул ук вакытта, Татарстан башкаласы Казан төрки халыкларны берләштерә, очраштыра торган урын буларак та билгеле. Минемчә, бу конкурсның башкалабыз Казанда үтүе шәһәребезне, республикабызны барлык төрки илләр арасында танытуда зур роль уйный.

Казанның «Татнефть-арена» боз сарае бу көннәрдә искиткеч үзгәрешләр дә кичерде. Бәйгене оештыручылар бар яктан да илебезнең, халкыбызның зәвык, матурлык, иминлек, төрле милләтләрнең гореф-гадәтләрен хөрмәт итүләрен дә күрсәтә алдылар. Бер сюжет сызыгы буенча барган китап уку, камилләшү, милләтеңне таныту кебек кызыл җеп булып узган идея бу конкурсны, чын мәгънәсендә эчтәлекле итеп, тамашачыны үзенә җәлеп итә алды. Шунысы да куанычлы: чыгышлар арасында, башка милләт вәкилләрен Казаныбыз белән таныштыру максатыннан, төрле видеосюжетлар тәкъдим ителде, шул ук вакытта, тамашада татар музыкасы мәдәнияте белән бәйле элементлар, нечкәлекләр күп булды. Финалга чыгу өчен, төрле илләрнең 25 төбәгеннән җырчылар үзләренең сәләтләрен күрсәтеп, иҗатта көчләрен сынашты. Конкурсның шартлары буенча һәр җырчының чыгышын 10 баллы система белән 25 илдән килгән жюри әгъзалары бәяләде.

Финалга бары тик 15 ил вәкиле генә сайлап алынды. Конкурста катнашучылар җырларын җанлы тавышка гына башкарды. Һәр катнашучы җырчы үз күңеленә хуш килгән, үз халкының милли яисә заманча җырларын тәкъдим итте. Татарстан өчен чыгыш ясаган Айдар Сөләйманов башкаруындагы «Атлар чаба» җырын зал алкышларга күмде. Айдарның номеры вакытында якты утлар, шар формасында ясалган декорациядә атлар чабышы анимациясе, шул шарга җырчының үзе дә менеп җырлавы тамашаны мавыктыргыч итте.

Бәйгедә катнашкан калган ил вәкилләре дә кимен куймады. Казахстан, Үзбәкстан, Албания, Гагаузия, Кыргызстан, Якутия, Төркия, Босния һәм Герцоговина, Башкорстан, Болгария, Мәскәү, Кырым артистлары сәхнәгә чыкты. Әмма халык һәм жюри күңелен Казахстан өчен чыгыш ясаган Жанар Дугалова яулады. Ул, 225 балл җыеп, «Turkvizion-2014» II халыкара телевизион җыр конкурсының абсолют җиңүчесе итеп игълан ителде. Татарстан егете А.Сөләйманов 201 балл белән икенчелекне яулады. Ә өченче урында – 199 балл иясе, Башкорстанның «Zaman» төркеме.

«Turkvizion-2014» дөньяны шаулаткан «Евровидение»дән бер дә ким булмады. Быелгы бәйгене 40 дөньяви телеканал күрсәтте. Һичшиксез, бәйге төрки телле мәдәниятне, милли һәм эстрада җыр жанрын үстерүгә зур этәргеч бирә.

**• Башваткыч**

**Илфия ТИМЕРГАЛИЕВА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты, 3 курс

## Казан федераль университетына багышланган кроссворд



Башваткычның җавапларын киләсе санда укыгыз.

### Сораулар:

*Сулдан уңга:*

1. Казан университеты кайсы император тарафыннан ачыла?
3. 1875-83 елларда университетта нинди мәктәп формалаша?
5. Университетның беренче ректоры (1805-13 еллар)?
7. Геологик музейга кем коллекцияләре белән нигез салына?
8. Университетның химия бинасы кайсы чиркәү урынына төзелгән?
11. Университет оештырылган беренче елларда ук ачылган музей.
13. КФУның хәзерге ректоры.
14. КФУның филиалы тагын кайсы шәһәрдә бар?
16. Университет составындагы күпчелек биналарны бизәп тора торган архитектура элементы.
18. «Казан университеты» (1970) поэмасының авторы.
19. Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты кайсы урамда урнашкан.
23. Студентларның «урак өсте».
24. Студентларның хезмәт хакы.

*Өстән аска:*

2. 1925 нче елда Казан университетына кем исеме бирелә?
4. Беренче унъеллыкта Казан университеты нинди телләрне өйрәнүдә әйдәүче үзәк булып торган?
6. Механика һәм математика институты кем исемен йөртә?
9. Төп бина кайсы урамда урнашкан?
10. Студентлар «авылы».
12. КФУ газетасы исеме.
15. КФУ студентлары шөгыльләнүче спорт комплексы.
17. КФУ президенты.
20. «Университет» сүзе кайсы телгә «Дарелфөнүн» дип тәрҗемә ителә?
21. Төп бина каршында урнашкан Ленин һәйкәле тирәсен студентлар ничек атыйлар?
22. КФУ составында ничә институт бар?
25. Университетта укыган, ләкин укуын тәмамламаган рус язучысы.
26. 2009 елдан оешкан, КФУ каршында эшләп килә торган бию коллективы.

**Газетаның 30 нчы октябрьдә (№31) басылып чыккан кроссвордның җаваплары:**

1) Коринфский
2) Клаус
3) Гимназия
4) Пара
5) Симонов
6) «Ленинец»
7) Дубяго
8) Потемкин
9) Арбузов
10) Гафуров
11) Лобачевский
12) Мәрьям
13) Уникс
14) Норден
15) Институт
16) Волков
17) Евклид
18) «Рутений»
19) Лингвистика
20) Пятницкий
21) Электрофизика
22) Бутлеров

Кызыл шакмакларда Казан Федераль Университет сүзләре килеп чыгачак.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.